# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

Сәүдә (эшләр башкару, хезмәтләр күрсәтү), сертификацияләү, лицензияләү өлкәсендә хокук бозган, мәҗбүри штрихлы кодлаштыру тәртибен һәм бәяләрнең дәүләт дисциплинасын бозган өчен административ җаваплылык турында Татарстан Республикасының аерым закон актларының үз көчләрен югалтуын тану хакында

**1 статья.** Түбәндәгеләрнең үз көчләрен югалтуын танырга:

«Сәүдә (эшләр башкару, хезмәтләр күрсәтү), сертификацияләү, лицензияләү өлкәсендә хокук бозган, мәҗбүри штрихлы кодлаштыру тәртибен һәм бәяләрнең дәүләт дисциплинасын бозган өчен административ җаваплылык турында» 1998 елның 3 июлендәге 1701 номерлы Татарстан Республикасы Законы (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1998, № 8 (I өлеш);

«Сәүдә (эшләр башкару, хезмәтләр күрсәтү), сертификацияләү, лицензияләү өлкәсендә хокук бозган, мәҗбүри штрихлы кодлаштыру тәртибен һәм бәяләрнең дәүләт дисциплинасын бозган өчен административ җаваплылык турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2000 елның 20 декабрендәге 545 номерлы Татарстан Республикасы Законы (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2000, № 12 (II) (II өлеш);

«Сәүдә (эшләр башкару, хезмәтләр күрсәтү), сертификацияләү, лицензияләү өлкәсендә хокук бозган, мәҗбүри штрихлы кодлаштыру тәртибен һәм бәяләрнең дәүләт дисциплинасын бозган өчен административ җаваплылык турында» Татарстан Республикасы Законын гамәлгә кертү тәртибе хакында» Татарстан Республикасы Дәүләт Советының 1998 елның 21

гыйнварендагы 1475 номерлы карары (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1998, № 8 (I өлеш).

**2 статья.** Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты — М.Шәймиев

Казан шәһәре,
2001 елның 27 сентябре
№ 1074